**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
**20 нче май 2025 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№45-05**

**Актаныш муниципаль районы Советының 2016 елның 04 августындагы 08-07 номерлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы милкендәге өченче зат хокукларыннан азат булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы милкендәге, өченче зат хокукларыннан азат булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегенә 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында (www.Aktanysh.tatarstan.ru ) һәм «Актаныш таңнары» район газетасында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Советының икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитетына йөкләргә.

Совет рәисе Л.Р.Зарипов